ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2022 п.г.т.Алексеевское № 516

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма Комитетының 07.08.2020 №311 «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Балигъ булмаганнарга аерым товарларны сатуны чикләүне билгеләү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән

**карар бирәм**:

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма Комитетының 07.08.2020 №311 «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында»гы карарының 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләргә, алар Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4 - 2.7, 2.12 - 2.13, 2.17, 2.19, 2.20, 3.2 - 3.6, 3.8, 3.10, 3.11, 3.14 - 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында каралган (Кушымта)».

2. Алексеевск муниципаль районы Башкарма Комитетының 07.08.2020 №311 «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында»гы карарының кушымтасын сүзләр белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| | **Статья 2.19 ТР КАХБ турында**<br>Татарстан Республикасы территориясендә тартмый торган тәмәке әйберләрен күпләп һәм ваклап сатуны тыюны бозу | - Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;<br>- Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы, белгече; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - «АТИ АМР РТ» МКУ житәкчесе. |
| | **Статья 2.20 ТР КАХБ турында**<br>Сыекландырылган углеводород газы булган товарларны гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен балигъ булмаганнарга ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук сыекландырылган углеводород газын сулап балигъ булмаганнарны куллануга җәлеп итү | - Башкарма комитет житәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;<br>- «АТИ АМР РТ» МКУ житәкчесе. |

3. Кадрлар эше өчен җаваплы (Демидова А.Д.) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затларның вазыйфаи инструкцияләренә үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хамзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет житәкчесе** **О.А. Гайнуллин**